Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге составына керүче
Чаллыбаш авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

23 ноябрь 2024 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Биектау авыл җирлеге составына керүче Чаллыбаш авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Чаллыбаш авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:
- урамнарны яктырту җайланмасы;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Биектау авылы, Х. Сафиуллин урамы, 4 йорт; Околоток-Яңасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт; Чаллыбаш авылы, М. Горький урамы, 69 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Сахапов Р.К.

Биектау авыл җирлеге башлыгы: Сахапов Р.К.